РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большие Нырты, ул. М.Джалиля, 13а
тел. (84362) 45-2-32

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
422063, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Нырты авылы, М.Җәлил урамы, 13а йорт
тел. (84362) 45-2-32

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
14.03.2019

КАРАР
№4

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Нырты авыл җирлегенең
милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы
нигезләмәне раслау хакында

Муниципаль милекне нәтиҗәле һәм рациональ файдалану максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы өстәлгән Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге Карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Олы Нырты авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://nirti.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.З.Сәфәраглиев

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Нырты авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары белән

14.03.2019 ел №4

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге милке турындагы**
**мәгълүматны ачу турында нигезләмә**

## 1. Төп нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең милек турындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмә "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында" 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, "Муниципаль сер турында" 1993 елның 21 июльендәге 5485-1 номерлы Федераль законнар нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милке турында мәгълүмат составын, шулай ук аны ачу тәртибен һәм вакытын билгели, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да.

1.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу дигәндә аңа кызыксынган барлык затларның да керә алуын тәэмин итү аңлашыла.

1.3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милекне исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә муниципаль норматив хокукый актлар белән бирелә. Мәгълүмат бирүдән баш тарту, соратып алына торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган очракта мөмкин.

1.4. Юридик затлар мәнфәгатьләренә зыян китерүдә мәгълүмат куллану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

1.5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль милке турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль милек реестрында теркәлгән мәгълүматлар күләмендә, шулай ук Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге милкендә булган җир кишәрлекләре турында мәгълүматлар бирелә.

1.6. Татарстан Республикасының муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматны тарату массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм сайтка "Интернет" челтәрендә урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат бирү кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да гамәлгә ашырыла.

## 2. Мәгълүматны тарату

2.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль милке турында мәгълүмат "Интернет" челтәрендә урнаштыру юлы белән

таратыла торган түбәндәге мәгълүматлар исемлеге белән билгеләнә (мондый мәгълүматлар закон белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган очраклардан тыш):

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль унитар предприятиеләре исемлеге (атамасы, урнашу урыны);

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы милкендә булган устав капиталы өлеше (акцияләр пакетлары), хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең атамасы, урыны, устав капиталында Саба муниципаль районы өлеше);

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәт (биналар) исемлеге (атамасы, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, куллануны чикләү, өченче затларның хокукларын йөкләү);

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы);

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыру прогноз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милке турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга мөмкин.

2.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар, финанс елы тәмамланганнан соң дүрт айдан да соңга калмыйча, 1 гыйнварга булган торышы буенча, лы Нырты авыл җирлегенең рәсми сайтында ел саен басылып чыгарга тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәт объектлары турындагы, аларны хосусыйлаштыру белән бәйле рәвештә, мәгълүматны ачу, хосусыйлаштыру турындагы законнар белән билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

## 3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милек Реестрында теркәлгән аерым милек объектлары (алга таба-исәпкә алу объектлары) буенча мәгълүмат, кызыксынган затларның мөрәҗәгате буенча хат рәвешендә яисә Татарстан Республикасы Саба муниципаль района Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милек Реестрыннан өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яки аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җиреленең Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып 30 көннән дә артмаган вакыт эчендә бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милек реестрыннан өземтәләр бирелә:

исәпкә алу объектларына ия булучыларга яки аларның законлы вәкилләренә;

исәпкә алу объекты хокук иясеннән яки аның законлы вәкиленнән ышаныч алган физик һәм юридик затларга;

Россия Федерациясе Хисап палатасына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына, Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасына;

җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясенең башка субъектларына;

дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнарга,

салым органнарына,

судларга, хокук саклау органнарына, суд приставларына-башкаручы, исәпкә алу объектлары һәм (яки) аларның хокукка ия булучылары белән бәйле эшләр булган, Федераль монополиягә каршы органга һәм Татарстан Республикасында аның территориаль органына.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милек реестрында исәпкә алу объектлары барлыгы турында мәгълүмат кына бирелә.

3.5. Язма формада бирелә торган соратып алына торган мәгълүматны бирүдән баш тарту дәлилләнгән булырга тиеш.

Соратып алына торган мәгълүмат бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәге сәбәпләр тора:

мөрәҗәгатьтә законнар белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган белешмәләр соратып алына;

мөрәҗәгатьнең эчтәлеге әлеге затны кызыксындырган мәгълүматны объектны берсүзсез билгеләргә мөмкинлек бирми;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль милек реестрында мәгълүматлары булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән булган.